**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО**
**РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**04.10.2019** **№ 1680**

**Биектау муниципаль районының Биектау тимер юл станциясе бистәсеннән 11 чакрымнан еарграк урнашкан ерак һәм халык саны аз булган авыл пунктларына беренче кирәк-ярак товарлары китерү белән бәйле кулланучылар кооперациясе оешмалары чыгымнарының бер өлешен кайтаруга Биектау муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр тәкъдим итү Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында**

“Конкуренцияне яклау турында”, 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль законның 15 ст. 1 б., Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш), шәхси эшмәкәрләргә, физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирүне җайга салучы норматив хокукый актлар, муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләр турында”, 2016 елның 6 сентябрендәге 887 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты, КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының 2018 елның 27 ноябрендәге 2583 номерлы карары белән расланган “Биектау муниципаль районының Биектау тимер юл станциясе бистәсеннән 11 чакрымнан еарграк урнашкан ерак һәм халык саны аз булган авыл пунктларына беренче кирәк-ярак товарлары китерү белән бәйле кулланучылар кооперациясе оешмалары чыгымнарының бер өлешен кайтаруга Биектау муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр тәкъдим итү Тәртибенә” түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.5 пунктында “теркәлгән һәм” сүзләрен бетерергә;

2) 1.6 пунктының 2 абзацында “Биектау муниципаль районы территориясендә теркәлгәннәргә” сүләрен “Россия Федерациясе налог органында тиешенчә итеп теркәлгән” сүзләре белән алмаштырырга.

3) 2.4 пунктының 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Комиссия тарафыннан уңай карар кабул ителгән очракта, баш бүлүче бюджет чараларын алучы буларак – Башкарма комитет һәм субсидияне алучы арасында, шулай ук башка оешма белән (әгәр дә әлеге таләп хокукый акт тарафыннан күз алдында тотылган булса) ТР Биектау муниципаль районы бюджетыннан, Россия Федерациясе финанслар министрлыгы тарафыннан билгеләнгән типик форма

нигезендә, билгеле субсидия төре өчен Россия Федерациясе субъекты финанс органы, муниципаль берәмлек финанс органы тарафыннан субсидия тәкъдим итү турында килешү (шартнамә) төзелә (алга таба – килешү).”.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы һәм Биектау муниципаль районы рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм урнаштырып халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарны контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф. Шәйдуллин